Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының утыз җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

7 декабрь, 2023 ел № 286

«2021-2025 елларга Питрәч муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында

«2021-2025 елларга Питрәч муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы турында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «2021-2025 елларга Питрәч муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Халыкның сәламәтлеген яхшырту, аларның тормыш сыйфатын яхшырту, иҗтимагый сәламәтлек культурасын формалаштыру, сәламәтлеккә җаваплы караш максатларында, Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

- балалар һәм яшүсмерләр өчен савыктыру һәм профилактика чараларын үткәрү, шулай ук гаиләне ныгыту һәм актив озак яшәүгә багышланган мәгълүмати-профилактик кампанияләр уздыру;

- Питрәч муниципаль районында эшләүче гражданнарның сәламәтлеген ныгыту чараларын үтәү;

- мәгълүмати-коммуникация кампаниясен уздыру юлы белән гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивациясе, шулай ук Питрәч муниципаль районы халкын һәм коммерциягә карамаган оешмаларын җәмәгать сәламәтлеген ныгыту чараларына җәлеп итү.

- «Вперед» («Алга») һәм «Интернет» челтәрендә программа чараларын тормышка ашыру барышы турында мәгълүмат бирү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов